СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт,
Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**от «30» сентябрь 2022 ел** **№ 22**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм түләү шартлары турында» Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 маендагы 29 номерлы карарына (30.12.2021 №38 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфа заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарлары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, урынбасарлары, аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Уставы нигезендә Ташкичү авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм түләү шартлары турында» Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 маендагы 29 номерлы карарына (30.12.2021 № 38 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 3 нче абзацын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәт хакы акчалата бүләкләү рәвешендә башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге башлыгы | 17944 |

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль учреждениеләрендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 12 абзацында (2 нче кушымта) «11 498 сум» сүзләрен «11 958 сум» сүзләренә алмаштырырга.

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 3 абзацын (4 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Баш хисапчының вазыйфаи оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән: |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш хисапчы | 19700 сум |

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Муниципаль вазыйфаны даими рәвештә биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы үзгәреш кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы үзгәреш кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 4 нче кушымтасындагы үзгәреш кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында җирлекләр бүлегенә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ